**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 22 сентябрь № 676

г. Казань

Татарстан Республикасы дәүләт архивлары хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәге теркәлгәннәрне расларга:

Дәүләт архивлары, документлар саклау үзәкләре, муниципаль берәмлекләр, ведомстволар, оешмалар архивлары, Татарстан Республикасы дәүләт архивларының архив документларын саклауны тәэмин итү лабораторияләре хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмә;

Татарстан Республикасы дәүләт архивларының гомумтармак эшче һөнәрләренең һәм гомумтармак җитәкче, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмә.

2. 2016 елның 1 сентябреннән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хезмәткә түләүнең тармак системаларын гамәлгә кертү, күрсәтелә торган бюджет хезмәтләренең нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын күтәрүгә юнәлдерелгән чаралар комплексы турында» 2007 ел, 22 октябрь, 584 нче карары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хезмәт өчен түләүләре Бердәм тариф челтәре нигезендә хисаплап чыгарыла торган Татарстан Республикасы бюджетыннан финансланучы оешмалар хезмәткәрләренә эш хакын арттыру турында» 2011 ел, 14 июнь, 477 нче карарының 3 – 5 пунктлары гамәле Татарстан Республикасы дәүләт архивлары хезмәткәрләренә кагылмый дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетына үзенең локаль норматив хокукый актларын әлеге карарга яраштырырга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы дәүләт архивлары хезмәткәрләре хезмәтенә түләү турында» 2007 ел, 20 сентябрь, 476 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт архивлары хезмәткәрләре хезмәтенә түләү турында» 2007 ел, 20 сентябрь, 476 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 ел, 22 декабрь, 910 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт архивлары хезмәткәрләре хезмәтенә түләү турында» 2007 ел, 20 сентябрь, 476 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 ел, 20 ноябрь, 882 нче.

5. Бу карарның гамәле 2016 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарала дип билгеләргә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\676.docx